РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ БОЛЬШЕНУРКЕЕВСКГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗУР НӨРКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**

2025 елның 10 апреле

**КАРАР**

№ 113

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 32 статьясы нигезендә, Совет Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге карар итте:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (1,2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын, аның график сурәтен дә кертеп, 2025 елның 15 апреленнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматын рәсми порталында бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә (pravo.tatarstan.ru), шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән (sarmanovo.tatarstan.ru), махсус мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрендә урнашкан, түбәндәге адрес буенча:

Зур Нөркәй ав., с.Рафиков ур., 32 й.

3. Карар халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Зур Нөркәй авыл җирлеге
Совет рәисе урынбасары

Х.Ш.Шайхеразиев